| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.10.2022 Баулы шәһәре №70

Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладларын күтәрү турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 90 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 140 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 55 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәре «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә аерым бюджет даирәсе оешмасының (бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган) структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазифаи окладь күләменә карата бермә-бер арттырыла, ул 11 958 сум тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров